КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 июль г.Казань № 857

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре реестрын алып бару турында» 2009 ел, 18 август, 567 нче карарына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанслар белән тәэмин ителүе үз керемнәре һәм Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне җирле бюджетлар тарафыннан сарыф итү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 5 август, 550 нче карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре реестрын алып бару турында» 2009 ел, 18 август, 567 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 май, 410 нчы; 2023 ел, 2 май, 551 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пункттагы «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанслар белән тәэмин ителүе үз керемнәре һәм Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне җирле бюджетлар тарафыннан сарыф итү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 5 август, 550 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин